# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Сарсак-Омга авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Сарсак-Омга торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

03.12. 2021 № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының районының «Сарсак-Омга авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Сарсак-Омга торак пунктында гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча 2021 елның 03 декабрендә 14:00 һәм 15:00 сәг уздырылган гражданнар җыены нәтиҗәләре турында түбәндәге сорау буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«2022 елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль «Сарсак-Омга авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Сарсак-Омга торак пункты территориясендә, I төркем инвалидлардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясендә хезмәт итүче һәм иректән мәхрүм итү урыннарындагы затлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәм балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым чаралары җыюны кертүгә һәм алардан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен файдалануга ризамы:

1. Сарсак-Омга авылында гомуми файдаланудагы юллар өчен вак таш сатып алу һәм юл ремонтлау;
2. Юлларны кардан чистарту;
3. Сарсак-Омга авылында халыкны су белән тәэмин итү өчен су үткәрү линиясе өчен ремонт, хезмәт күрсәтү, материаллар сатып алу;
4. Җирләү урыннарын оештыру һәм карап тоту (зират коймасын яңарту һәм шартнамә буенча түләү);
5. Сарсак-Омга авылындагы авыл мәдәният йорты коймасын һәм авылга керү аншлагын яңарту һәм ремонтлау

«РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 409 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны - 213 кеше, бу 52 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"РИЗА" позициясе өчен гражданнар җыенында 213 катнашучы тавыш бирде;
"КАРШЫ" позициясе өчен җыенда 0 катнашучы тавыш бирде.

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Сарсак-Омга авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Сарсак-Омга торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - дөрес дип танырга.

2. 2022 елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Сарсак-Омга авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Сарсак-Омга торак пункты территориясендә, I төркем инвалидлардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясендә хезмәт итүче һәм иректән мәхрүм итү урыннарындагы затлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәм балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым чаралары җыюны кертергә.

3. Җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

1. Сарсак-Омга авылында гомуми файдаланудагы юллар өчен вак таш сатып алу һәм юл ремонтлау;

2. Юлларны кардан чистарту;

3. Сарсак-Омга авылында халыкны су белән тәэмин итү өчен су үткәрү линиясе өчен ремонт, хезмәт күрсәтү, материаллар сатып алу;

4. Җирләү урыннарын оештыру һәм карап тоту (зират коймасын яңарту һәм шартнамә буенча түләү);

5. Сарсак-Омга авылындагы авыл мәдәният йорты коймасын һәм авылга керү аншлагын яңарту һәм ремонтлау.

4. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендында элеп халыкка җиткерергә, “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (https://www.agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Авыл җирлеге башлыгы Т.С.Николаева

Совет Сарсак-Омгинского сельского поселения
Сарсак-Умга авыл җирлеге Советы
ИНН 1601002565
АГРЫЗСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН · ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ